РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

20.04.2018 №81-п

Саба муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

“Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексына һәм “Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарына административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген билгеләү буенча Татарстан Республикасының дәүләт вәкаләтләрен бирү хакында" Татарстан Республикасы Законының 1 статьясына үзгәрешләр кертү турында” 2018 елның 19 мартында кабул ителгән 14-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына туры китереп, шул исәптән Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы Кодексының, 2017 елның 29 декабрендәге 463-ФЗ номерлы Федераль законның 3.6 статьясы таләпләрен тулыландырган төп фикерләрен исәпкә алып (муниципаль төзекләндерү кагыйдәләрен бозу), транспорт чараларын яшелләндерелгән территорияләрдә, балалар һәм спорт мәйданчыкларында, хайваннар йөртү өчен мәйданчыкларда, шулай ук йорт янындагы территориядәге хуҗалык мәйданчыкларында урнаштырган өчен җаваплылык билгеләүче яңа 3.17 статья белән тулыландырылуы сәбәпле,

КАРАР БИРӘМ:

1. Саба муниципаль районы Башлыгының “Саба муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеген раслау турында” 06.04.2016 ел 53-п номерлы карарына (04.12.2017 ел 207-п номерлы карары редакциясендә), кушымтаны яңа редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә (теркәлә).

2. Әлеге карарны Интернет челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматлар рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы муниципаль берәмлекләре порталы составында Саба муниципаль районы рәсми сайтында (http://saby.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшерүдә тотуны Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесенә йөкләргә.

Р.Н. Минниханов

КУШЫМТА
Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Башлыгының
«20» 04 2018 ел 81-п номерлы
карарына

Саба муниципаль районында административ хокук бозулар турында беркетмәләр төзүгә вәкаләтле вазыйфаи затлар исемлеге

| *ТР АХБтК статьялары* | *Вазыйфаи затлар исемлеге* |
|---|---|
| **Статья 2.1**<br>Телләр турында Татарстан Республикасы законнарын бозу (Юл күрсәткечләрен һәм башка күрсәткечләрне, билгеләмәләрне, адрес атрибутикасын, башка визуаль мәгълүматны рәсмиләштергәндә һәм урнаштырганда телләр турында Татарстан Республикасы законнары таләпләрен үтәмәгән өчен, шулай ук телләр турында Татарстан Республикасы законнарын гражданнарның хокукларын һәм ирекләрен бозуга яисә гражданнарның тел билгесе буенча хокукларын чикләүгә китерерлек итеп бозган өчен) | - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының тәртип саклау җәмәгать пунктлары эшчәнлеген тәэмин итүче әйдәп баручы белгече;<br>- Саба муниципаль районы икътисад бүлеге баш белгече. |
| **Статья 2.4**<br>Татарстан Республикасы дәүләт символларына карата законсыз гамәлләр | - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының тәртип саклау җәмәгать пунктлары эшчәнлеген тәэмин итүче әйдәп баручы белгече. |
| **Статья 2.5**<br>Татарстан Республикасы дәүләт бүләкләрен законсыз әзерләү яисә йөртү | - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының тәртип саклау җәмәгать пунктлары эшчәнлеген тәэмин итүче әйдәп баручы белгече. |
| **Статья 2.6**<br>Җирле үзидарә органнарының муниципаль хокукый актларын үтәмәү<br>**Статья 2.7** | - Саба муниципаль районы Советының юридик бүлеге начальнигы;<br>- Саба муниципаль районы Башкарма комитетының тәртип саклау җәмәгать пунктлары эшчәнлеген тәэмин итүче әйдәп баручы белгече. |

| | |
|---|---|
| Муниципаль берәмлекләрнең рәсми символларыннан файдалану тәртибен бозу | |
| **Статья 2.8**<br>Сату һәм (яисә) реализацияләү максатларында өй шартларында этил спиртлы продукция җитештерү | - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының тәртип саклау җәмәгать пунктлары эшчәнлеген тәэмин итүче әйдәп баручы белгече. |
| **Статья 2.12**<br>Гражданнарны социаль ипотека системасында торак шартларын яхшыртуга мохтаҗлар буларак исәпкә кую кагыйдәләрен һәм тәртибен бозу<br>**Статья 2.13**<br>Гражданнарны социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗлар буларак исәпкә кую һәм исәпне алып бару тәртибен бозу | - Саба муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы көрәш мәсьәләләре буенча ярдәмчесе;<br>- Саба муниципаль районы Башкарма комитетының тәртип саклау җәмәгать пунктлары эшчәнлеген тәэмин итүче әйдәп баручы белгече. |
| **Статья 2.14**<br>Тартмый торган тәмәке әйберләре белән Татарстан Республикасы территориясендә күпләп һәм ваклап сәүдә итүне тыюны бозу | - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының тәртип саклау җәмәгать пунктлары эшчәнлеген тәэмин итүче әйдәп баручы белгече. |
| **Статья 3.2**<br>Урам сәүдәсен оештыру тәртибен бозу<br>**Статья 3.5**<br>Тышкы мәгълүматны урнаштыру тәртибен бозу | - Саба муниципаль районы икътисад бүлеге баш белгече;<br>- Саба муниципаль районы Башкарма комитетының тәртип саклау җәмәгать пунктлары эшчәнлеген тәэмин итүче әйдәп баручы белгече. |
| **Статья 3.3**<br>Җир асты коммуникацияләрен тоту кагыйдәләрен бозу<br>**Статья 3.4**<br>Урамны, квартал эчен яктырту кагыйдәләрен бозу<br>**Статья 3.6**<br>Җирлекләр һәм шәһәр округлары территорияләрен төзекләндерүнең муниципаль кагыйдәләрен, калдыклар белән эш итүнең муниципаль кагыйдәләрен бозу<br>**Статья 3.17**<br>Транспорт чараларын яшелләндерелгән территорияләрдә, балалар һәм спорт мәйданчыкларында, хаваннар йөртү өчен | - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктур үсеш бүлеге начальнигы урынбасары;<br>- Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктур үсеш бүлеге баш белгече;<br>- Саба муниципаль районы Башкарма комитетының тәртип саклау җәмәгать пунктлары эшчәнлеген тәэмин итүче әйдәп баручы белгече. |

| | |
|---|---|
| мәйданчыкларда, шулай ук йорт янындагы территориядә урнашкан хуҗалык мәйданчыкларында урнаштыру | |
| **Статья 3.7**<br>Этләрне урамда йөртү тәртибен бозу | - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктур үсеш бүлеге начальнигы урынбасары;<br>- Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктур үсеш бүлеге баш белгече;<br>- Саба муниципаль районы Башкарма комитетының тәртип саклау җәмәгать пунктлары эшчәнлеген тәэмин итүче әйдәп баручы белгече. |
| **Статья 3.8**<br>Төнлә гражданнарның тынычлыгын һәм тынлыкны бозу | - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының тәртип саклау җәмәгать пунктлары эшчәнлеген тәэмин итүче әйдәп баручы белгече. |
| **Статья 3.10**<br>Татарстан Республикасы территориясендә су объектларында кешеләр гомерен саклау кагыйдәләрен бозу | - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының тәртип саклау җәмәгать пунктлары эшчәнлеген тәэмин итүче әйдәп баручы белгече. |
| **Статья 3.11**<br>Балаларның сәламәтлегенә һәм аларның үсешенә зыян китерүне кисәтү чараларын тәэмин итү таләпләрен үтәмәү | - балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе җаваплы секретаре;<br>- Саба муниципаль районы Башкарма комитетының тәртип саклау җәмәгать пунктлары эшчәнлеген тәэмин итүче әйдәп баручы белгече. |
| **Статья 3.14**<br>Мәдәни-тамаша чараларында булганда иҗтимагый тәртипне бозу | - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының тәртип саклау җәмәгать пунктлары эшчәнлеген тәэмин итүче әйдәп баручы белгече. |
| **Статья 3.15**<br>Җәмәгать урыннарында гражданнарга бәйләнү | - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының тәртип саклау җәмәгать пунктлары эшчәнлеген тәэмин итүче әйдәп баручы белгече. |
| **Статья 3.16**<br>Транспорт чараларын түләүле муниципаль парковкада (парковка урыннарында) урнаштырган өчен түләмәү | - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының тәртип саклау җәмәгать пунктлары эшчәнлеген тәэмин итүче әйдәп баручы белгече. |
| **Статья 4.4**<br>Муниципаль милектәге торак булмаган фонд объекты белән эш итү һәм күрсәтелгән объекттан файдалану тәртибен бозу | - Саба муниципаль районы Мөлкәт һәм җир палатасы баш белгече;<br>- Саба муниципаль районы Башкарма комитетының тәртип саклау җәмәгать пунктлары эшчәнлеген тәэмин итүче әйдәп баручы белгече. |

| | |
|---|---|
| **Статья 5.1**<br>Билетсыз йөрү<br>**Статья 5.2**<br>Багаж йөртү кагыйдәләрен бозу<br>**Статья 5.6**<br>Пассажирны йөртүдән баш тарту | - Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктур үсеш бүлеге начальнигы урынбасары;<br>- Саба муниципаль районы Башкарма комитетының инфраструктур үсеш бүлеге баш белгече;<br>- Саба муниципаль районы Башкарма комитетының тәртип саклау җәмәгать пунктлары эшчәнлеген тәэмин итүче әйдәп баручы белгече. |